| Республика Татарстан<br>Совет Петровско-Заводского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Петровский Завод<br>җирлеге Советы |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ<br>20 апрель 2022 ел | КАРАР<br>№4 |
|---|---|

**«Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 23 июлендәге 15 номерлы Петровский Завод авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Петровский Завод авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2007 елның 23 июлендәге 15 номерлы Совет карары белән расланган Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карар Әлмәт авыл җирлеге советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.

Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;
2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;
3) сораштыру үткәрү методикасы;
4) сораштыру кәгазенең (сораштыру исемлегенең) формасы;
5) сораштыруда катнашучы муниципаль район халкының минималь саны.
6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

2) 22 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге бюджеты - җирле үзидарә органнары яки муниципаль район халкы инициативасы белән сораштыру уздырганда».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Совет Рәисе А.Б. Хөснетдинов